| | Кызыл Юл | кварталлар: 8, 9, 13, 18, 27, 28, 36-38, 49, 56, 65-68, квартал өлешләре: 1-7, 10-12, 14-17, 19-26, 29-35, 39-48, 50-55, 57-64, 69-79 | 6188 |
| | Ләке | кварталлар: 1-3, 8, 10, 11, 14, 21, 31, 32, 36, 39, 40, 42, 57, 59, 90, 92-94, 117, 120, 121, 123-125, 127, 129, 131, квартал өлешләре: 4-7, 9, 12, 13, 15-20, 22-30, 33-35, 37, 38, 41, 43-50, 52, 54-56, 58, 60-68, 71-75, 77, 81, 82, 89, 91, 95-116, 118, 119, 122, 126, 128, 130, 132 | 8185 |
| | Җәмгысе | | 26537 |
| 10. Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү (Россия Федерациясе Урман кодексының 25, 39 статьялары) | Баграж | 1, 2, 4-53, 55-63, 70-101 | 8916 |
| | Биклән | 1-40, 42-48, 50-59, 64-119 | 8440 |
| | Ворошилов | 1-71 | 6622 |
| | Кызыл Юл | 1-79 | 9098 |
| | Ләке | 1-50, 52, 54-82, 86, 89-132 | 10410 |
| | Җәмгысе | | 43486 |
| 10.1. Урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү (Россия Федерациясе Урман кодексының 25, 39.1 статьялары) | Баграж | 1, 2, 4-53, 55-63, 70-101 | 8916 |
| | Биклән | 1-40, 42-48, 50-59, 64-119 | 8440 |
| | Ворошилов | 1-71 | 6622 |
| | Кызыл Юл | 1-79 | 9098 |
| | Ләке | 1-50, 52, 54-82, 86, 89-132 | 10410 |
| | Җәмгысе | | 43486 |
| 11. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару (Россия Федерациясе Урман кодексының 25, 43 статьялары) Тыела: урман парклары зоналары, яшел зоналар, шәһәр урманнары. | Баграж | 1, 2, 4-53, 55-63, 80-95, 99-101 | 7861 |
| | Биклән | кварталлар: 40, 42-48, 50-56, 58, 59, 64-114, 116-119, квартал өлешләре: 36, 115 | 5020 |
| | Ворошилов | 1-71 | 6622 |
| | Кызыл Юл | 1-79 | 9098 |
| | Ләке | 1-50, 52, 54-82, 86, 89-132 | 10410 |
| | Җәмгысе | | 39011 |

| Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Кишәрлек урманчылыгының атылышы | Кварталлар яки аларның өлешләре исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 12. Сусаклагычлар, башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү (РФ Урман кодексының 25, 44 статьялары) | Баграж | 1, 2, 4-53, 55-63, 70-101 | 8916 |
| | Биклән | 1-40, 42-48, 50-59, 64-119 | 8440 |
| | Ворошилов | 1-71 | 6622 |
| | Кызыл Юл | 1-79 | 9098 |
| | Ләке | 1- 50, 52, 54-82, 86, 89-132 | 10410 |
| | Җәмгысе | | 43486 |
| 13. Линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү (Россия Федерациясе Урман кодексының 25, 45 статьялары) Тыела: урман паркы зоналары. * Гамәлдәге линияле объектлар, шул исәптән, Россия Федерациясе Урман кодексынд әлеге куллану төре буенча чикләүләр кертелгән яклагыч урманнар категориясендә дә кулланылырга мөмкин | Баграж | 1, 2, 4-53, 55-63, 70-101 | 8916 |
| | Биклән | 1-40, 42-48, 50-59, 64-119 | 8440 |
| | Ворошилов | 1-71 | 6622 |
| | Кызыл Юл | 1-79 | 9098 |
| | Ләке | 1-50, 52, 54-82, 86, 89-132 | 10410 |
| | Җәмгысе | | 43486 |
| 14. Агач материалы һәм башка урман ресурслары эшкәртү (Россия Федерациясе Урман кодексының 25, 46 статьялары) Тыела: яклаучы урманнар, МСК | Баграж | кварталлар: 7-9, 12-15 ,22-24, 26, 30, 33-35, 42, 87, 88, квартал өлешләре: 4-6, 10, 11, 16-20, 21, 25, 27-29, 31, 32, 36-41, 43-53, 91, 93, 94, 95 | 4901 |
| | Биклән | кварталлар: 66, 68, 81, 91, 95, 96, 104-106, квартал өлешләре: 67, 78-80, 82-90, 92-94, 97-103, 107-110, 115, 117, 119 | 1958 |
| | Ворошилов | кварталлар: 2, 7, 8, 11, 12, 15, 17, 21-23, 30, 31, 36, 38-40, 42, 46, 48, 52, 53, квартал өлешләре: 1, 3-6, 9, 10, 13, 14, 16, 18-20, 24-29, 32-35, 37, 41, 43-45, 47, 49-51, 54-61, 67, 68, 70, 71 | 5305 |
| | Кызыл Юл | кварталлар: 8, 9, 13, 18, 27, 28, 36-38, 49, 56, 65-68, квартал өлешләре: 1-7, 10-12, 14-17, 19-26, 29-35, 39-48, 50-55, 57-64, 69-79 | 6188 |
| | Ләке | кварталлар: 1-3, 8, 10, 11, 14, 21, 31, 32, 36, 39, 40, 42, 57, 59, 90, 92-94, 117, 120, 121, 123-125, 127, 129, 131, квартал өлешләре: 4-7 ,9, 12, 13, 15-20, 22-30, 33-35, 37, 38, 41, 43-50, 52, 54-56, 58, 60-68, 71-75, 77, 81, 82, 89, 91, 95-116, 118, 119, 122, 126, 128, 130, | 8185 |

| Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Кишәрлек урманчылыгының атылышы | Кварталлар яки аларның өлешләре исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | 132 | |
| | Җәмгысе | | 26537 |
| 15. Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру (Россия Федерациясе Урман кодексының 25, 47 статьялары) | Баграж | 1, 2, 4-53, 55-63, 70-101 | 8916 |
| | Биклән | 1-40, 42-48, 50-59, 64-119 | 8440 |
| | Ворошилов | 1-71 | 6622 |
| | Кызыл Юл | 1-79 | 9098 |
| | Ләке | 1-50, 52, 54-82, 86, 89-132 | 10410 |
| | Җәмгысе | | 43486 |
| 16. Россия Федерациясе Урман кодексының 6 статьясының 2 өлеше нигезендә билгеләнгән бүтән төрләре | Баграж | 1, 2, 4-53, 55-63, 70-101 | 8916 |
| | Биклән | 1-40, 42-48, 50-59, 64-119 | 8440 |
| | Ворошилов | 1-71 | 6622 |
| | Кызыл Юл | 1-79 | 9098 |
| | Ләке | 1-50, 52, 54-82, 86, 89-132 | 10410 |
| | Җәмгысе | | 43486 |

3. 2 бүлектә:

а) 2.1 бүлекчәдә:

2.1.1 бүлекчәдә 6 нчы таблицаның кырык сигезенче, йөз дә беренче, йөз илле бишенче һәм ике йөз унынчы юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| |
|---|
| Яклагыч урманнар категориясе – яклагыч урман полосаларында урнашкан урманнар (тимер юл транспорты турында Россия Федерациясе законнары, автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында законнар нигезендә билгеләнгән тимер юлларга бүлеп бирелгән полосалар чикләрендә һәм автомобиль юлларының юл буе полосаларында урнашкан урманнар) |
| Яклагыч урманар категориясе – урман-дала урманнары (дала зонасында, урман-дала зонасында урнашкан, саклау функцияләрен үти торган урманнар) |
| Яклаучы урман категорияләре – урман паркы зоналарында урнашкан урманнар |
| Яклаучы урман категорияләре – яшел зоналарда урнашкан урманнар |

2.1.6 бүлекчәдә «2016 елның 29 июнендәге 375 номерлы» сүзләрен «2019 елның 25 мартындагы 188 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2.8 бүлектә:

2.8.1 бүлекчәнең икенче абзацында «вакытлы корылмалар» сүзләрен «капиталь булмаган төзелмәләр һәм корылмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.8.2 бүлекчәнең «Чикләрендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру объектларын төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү күздә тотылган урманнарны үзләштерүнең планлаштырыла торган зоналары» дигән таблицага киләсе эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Түбән Кама | Биклән | 1 | «Кама» балаларны савыктыру лагере | Үзгәртеп кору максатларында физкультура-савыктыру корылмаларын төзү планлаштырыла |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Түбән Кама | Кызыл Юл | 71 | Зәй муниципаль районы «Созвездие» балаларны савыктыру лагере» МБУ | Үзгәртеп кору максатларында физкультура-савыктыру корылмаларын төзү планлаштырыла |

2.8.4 бүлекчәнең атамасында «вакытлы корылмалар» сүзләрен «капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.8.5 бүлекчәнең дүртенче абзацында «вакытлы корылмалар» сүзләрен «капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар» сүзләренә алмаштырырга;

1) 2.12 бүлектә:

атамасында «җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен эшләрне башкару» сүзләрен «җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

беренче-бишенче абзацларда, унбишенче абзацларда «җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен эшләрне башкару» сүзләрен «җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен эшләрне башкару» сүзләрен «җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

г) 2.17 бүлектә:

2.17.1 бүлекчәдәге «Янгынга каршы төзекләндерү чараларының күләме» таблицасынның 5.1 һәм 5.3 юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5.1. | Янгынга каршы тәэминат чыганакларына килү юллары ясау | данә | 0 |
| 5.3. | Янгын сүндерү сулыклары ясау | данә | 0 |

2.17.3 бүлекчәдә:

сигезенче, тугызынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Урманнарны торгызу Россия Федерациясе Урман кодексының 61, 62 статьялары, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2019 елның 25 мартындагы 188 номерлы боерыгы белән расланган Урманнарны торгызу кагыйдәләре (алга таба – Урманнарны торгызу кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны үрчетү Россия Федерациясе Урман кодексының 63 статьясы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2018 елның 28 декабрендәге 700 номерлы боерыгы белән расланган Урманнарны үрчетү кагыйдәләре (алга таба – Урманнарны үрчетү кагыйдәләре) нигезендә башкарыла. Урманчылыкта төп урман барлыкка китерүче токымнар булып гади нарат, Европа

чыршысы, Себер карагае, сабакчалы имән, вак яфраклы юкә, иенке каен, гади усак, гади корычагач тора.»;

4. 3 бүлектә:

а) 3.**1** бүлекнең 18 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 нче таблица

Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләмәләр

| Тәртип саны | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Яклагыч урманнар | Яклагыч урманнарда тоташ кисүләрне уздыру әлеге Кодексның 21 статьясының 5.1 өлешендә каралган очракларда һәм сайланма кисүләр үзләренең тиләлек хасил итә, су саклый торган, санитар-гигиеник, савыктыру һәм башка төрле функцияләрен югалта башлаган урман утыртмаларын яклагыч урманнарның максатчан билгеләнешен һәм алар башкара торган файдалы вазыйфаларны саклауны тәэмин итә торган урман утыртмаларына алмаштыруны тәэмин итмәгән очракларда гамәлгә ашырыла, әгәр әлеге Кодекста башкача билгеләнмәсә. |
| 2. | су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Тыела:<br>1) агулы химик препаратлар куллану;<br>2) авыл хуҗалыгы алып бару, умартачылык һәм печән чабудан гайре;<br>3) урман плантацияләре төзү һәм алардан файдалану;<br>4) линияле объектлардан, гидротехник корылмалардан һәм нефть һәм табигый газ табу, эзләү һәм чыгару өчен кирәкле объектлардан кала, капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану. |
| 3. | Табигый һәм башка төр объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнар<br><br>а) яклагыч урман полосаларында урнашкан урманнар (тимер юл транспорты турында Россия Федерациясе законнары, автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында законнар нигезендә билгеләнгән тимер юлларга бүлеп бирелгән полосалар чикләрендә һәм автомобиль юлларының юл буе полосаларында урнашкан урманнар)<br><br>б) урман паркы зоналарында урнашкан урманнар (урман | <br><br><br><br>Тыела:<br>1) техник регламентта каралганнан киңрәк итеп линияле корылмалар кисү;<br>2) урман түшәмәсен белән мүк җыю һәм әзерләү.<br><br><br><br><br><br><br><br><br>Тыела:<br>1) агулы химик препаратлар куллану; |

| Тәртип саны | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | фонды җирләрендә һәм халыкның ялын оештыру, санитария-гигиена, савыктыру функцияләрен һәм табигый ландшафтларның эстетик кыйммәтен саклау максатларында кулланыла торган башка категория җирләрендә урнашкан урманнар)<br><br>в) яшел зоналарда урнашкан урманнар (халыкны табигый һәм техноген чыгышның тискәре күренешләре йогынтысыннан яклауны тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм торгызу максатларында бүлеп бирелә торган урман фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрендә урнашкан урманнар) | 2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару;<br>5) капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану, линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан тыш;<br><br>Тыела:<br>1) агулы химик препаратлар куллану;<br>2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;<br>3) файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару;<br>4) авыл хуҗалыгын алып бару, печән чабу һәм умартачылыктан гайре, шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында коймалар кую;<br>5) капиталь төзелеш объектлары төзү һәм алардан файдалану, гидротехника корылмаларыннан, элемтә линияләреннән, электрүткәргеч линияләрдән, җир асты торбаүткәргечләреннән гайре; |
| 4. | Кыйммәтле урманнар | Линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан кала, капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану тыела.<br>Су объектлары буйларында урнашкан яклагыч урман полосаларында линияле объектлардан, гидротехника корылмаларыннан һәм нефть һәм табигый газ табу, эзләү һәм чыгару өчен кирәкле объектлардан кала, капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану тыела.<br>Чикләвекле-кәсепчелек зоналарында урнашкан урманнарда агач материалы әзерләү тыела. |
| 5. | Эксплуатация урманнары | Урманнардан файдалануның барлык төрләре дә рөхсәт ителә. |

б) 3.2 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус саклана торган урманнарның хокукый режимы Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 119 статьясы белән регламентлана.

Махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә аларның максатчан билгеләнеше белән файдалы үзлекләренә ярашмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыру тыела.

Махсус яклана торган урман кишәрлекләре төрләре буенча чикләмәләр 19 нчы таблицада күрсәтелде.

19 нчы таблица

Махсус яклана торган урман кишәрлеге төрләре буенча чикләмәләр

| Тәртип саны | Махсус яклана торган урман кишәрлекләре төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су объектлары, чокыр сөзәклекләрендә урнашкан ярсаклагыч, туфраксаклагыч урман кишәрлекләре | Махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә, Россия Федерациясе Урман кодексының 119 статьясының 3 өлешендә күрсәтелгәннәрдән тыш, түбәндәгеләр тыела:<br>1) әлеге Урман Кодексының 17 статьясының 4 өлешендә, 21 статьясының 5.1 өлешендә каралган очраклардан тыш, урман утыртмаларына тоташ кисүләр үткәрү;<br>2) авыл хуҗалыгы алып бару, умартачылык һәм печән чабудан гайре;<br>3) капиталь төзелеш объектлары урнаштыру, линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан тыш.<br>3. Махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә сайланма кисүләр уздыру фәкать һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү максатларында гына уздырыла. |
| 2. | Урмансыз киңлекләр белән чиктәш булып торучы урман кырыйлары | |
| 3. | Урман-орлык плантацияләре, даими урман-орлык кишәрлекләре һәм урман орлыкчылыгының башка объектлары | |
| 4. | Реликт һәм эндемик үсемлекләре булган урман кишәрлекләре | |
| 5. | Сирәк һәм югалу куркынычы янаган кыргый җәнлекләрнең яшәү урыннары | |
| 6. | Махсус яклanучы башка урман кишәрлекләре | |
| 7. | Тыюлы урман кишәрлекләре | Тыюлы урман кишәрлекләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>1) урман утыртмаларын кисү;<br>2) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратлары куллану;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылма ятмаларын эшкәртү;<br>5) капиталь төзелеш объектлары урнаштыру |

Искәрмә: Махсус яклана торган урман кишәрлекләре урнашкан җир һәм аларның мәйданы урманнар коруны проектлаганда күрсәтелә.»;

в) 3.3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләмәләр түбәндәге таблицада китерелде.

| Тәртип саны | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Агач әзерләү | Файдалану өчен исәпкә алынган диләнкене (агач материалы алуның мөмкин булган күләменнән) артып китә торган күләмдә, шулай ук кисентеләрнең яшен бозып, агач материалы әзерләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 29 статьясының 4 |

| Тәртип саны | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | өлеше). Россия Табигать министрлыгының 2016 елның 13 сентябрендәге 474 номерлы боерыгы белән расланган Агач материалы әзерләү кагыйдәләре нигезендә:<br>а) елга һәм чишмә үзәннәрен сөйрәмә җир трассалары һәм урман юллары сыйфатында куллану рөхсәт ителми;<br>б) диләнкедән читтә урман утыртмаларын, үсемчелек катламын һәм туфракларны зарарлау, урманнарны сәнәгать һәм башка төрле калдыклар белән чүпләү рөхсәт ителми;<br>в) юлларны, күперләрне һәм ызаннарны, шулай ук киптерүче челтәрне, юл, гидромелиоратив һәм башка корылмаларны, су агымнарын, чишмәләрне, елгаларны саклау мөһим;<br>г) аударылыган һәм асылынып төшкән, киселгән агачларны (киселгән һәм диләнкедә калдырылган агачларны исәпкә алып) калдыру, сакланырга тиешле яшь шытымны зарарлау яисә һәлак итү тыела;<br>д) чик, квартал, диләнке баганаларын һәм башкаларын, агачларда һәм түмәрләрдәге тамгаларны, ярлыкларны һәм саннарны бетерү яисә зарарлау тыела;<br>е) кисүгә тиешле булмаган һәм Россия Федерациясенең Агач материалы әзерләү кагыйдәләре һәм урман законнары нигезендә сакланырга тиешле агачларны, шул исәптән орлык бирү чыганакларын һәм плюс агачларын кисү һәм зарарлау тыела;<br>ж) рөхсәт ителгән вакыты (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) тәмамлангач үзагач әзерләү, шулай ук файдалану хокукы туктатылгач яисә тәмамлангач үзагач әзерләү рөхсәт ителми;<br>з) билгеләнгән вакытына (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) алып чыгылмаган агач материалын диләнкедә калдыру рөхсәт ителми;<br>и) диләнке ясауның технологик картасында каралмаган урыннарга агач материалы чыгару, тарттыру рөхсәт ителми;<br>к) диләнке чистарту эшләрен үтәмәү яисә үз вакытында үтәмәү рөхсәт ителми;<br>л) сөйрәмә җирләрдән һәм төяү мәйданнарыннан кала, туфракның өске уңдырышлы катламын юк итү рөхсәт ителми.<br>Диләнкеләрдә үзагач әзерләгәндә яшәргә яраклы, аларның табигый ареалы чикләрендә үсеп китүче (әгәр дә тиешле агач токымының урманнар составындагы мәйданы өлеше урманчылык мәйданының 1 процентыннан артып китмәсә) кыйммәтле агач токымнарын (имән, бук, корычагач, эрбет, юкә, күг, элмә, кара зирек, чәчә торган каштан) кисү рөхсәт ителми.<br>Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән зат төрләре |

| Тәртип саны | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | сакланырга тиешле.<br>Агач материалы әзерләгәндә урман утыртмалары агачлары составында өч һәм аннан да күбрәк берәмлектә эрбет булган, өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисү рөхсәт ителми. |
| 2. | Чәер әзерләү | Түбәндәгеләргә кирт салу тыела:<br>а) юкка чыгарганчыга кадәр зарарлы организм чыганакларында урнашкан урман утыртмаларына;<br>б) урман янгыннары, зарарлы организмнар һәм башка тискәре факторлар нәтиҗәсендә зарарланган һәм зәгыйфьләнгән урман утыртмаларына;<br>в) Россия Федерациясе законнары нигезендә үзагач әзерләү максатында өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын тоташ яки сайланма кисүләр рөхсәт ителмәгән урманнардагы урман утыртмаларына;<br>г) даими урман-орлык кишәрлекләрендә, урман-орлык плантацияләрендә, генетика резервацияләрендә урнашкан урман утыртмаларына, шулай ук плюс агачларына, орлыклыкларга, орлык чәчәклекләренә һәм полосаларына (2012 елның 24 гыйнварындагы 23 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Чәер әзерләү кагыйдәләренең 7 пункты). |
| 3. | Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу | Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу өчен үсемлекләрнең түбәндәге төрләрен куллану тыела:<br>– Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрне;<br>– наркотик матдәләр дип танылучыларны;<br>– агачын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгәннәрне.<br>Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу чикләнергә яки радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә тыелырга мөмкин.<br>Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2018 елның 16 июлендәге 325 номерлы боерыгы белән расланган Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю кагыйдәләре нигезендә:<br>- эрозиягә каршы урманнарда; су объектлары, чокыр авышлыклары буйларында урнашкан ярсаклагыч һәм туфраксаклагыч урман кишәрлекләрендә, шулай ук тулылыгы 0,8-1,0гә тигез булган яшь агачларда һәм йомылмаган урман культураларында түмәр сагызын әзерләү рөхсәт ителми (13 пункт);<br>– агачларны туз әзерләү өчен кисү тыела (14 пункт);<br>- урманнарда табигый һәм башка төрле объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урман түшәмәләрен җыярга рөхсәт ителми (20 пункт). |
| 4. | Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару | Төрләре Кызыл китапка, Татарстан Республикасы кызыл китабына кертелгән яки наркотик матдәләр булып |

| Тәртип саны | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | үләннәре җыю | саналган гөмбәләрне һәм кыргый үсүче үсемлекләрне әзерләү һәм җыеп алу рөхсәт ителми.<br>Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнергә мөмкин.<br>2011 елның 5 декабрендәге 511 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу кагыйдәләре нигезендә:<br>– җимеш бирә торган агачларны кисү һәм җимешләр әзерләү өчен ботакларны кискәләү тыела (14 пункт);<br>– чикләвекләрне әзерләгәндә агачларны һәм куакларны кисү, шулай ук агачларга һәм куакларга зыян сала торган ысулларны куллану тыела (15 пункт);<br>- гөмбәләр әзерләү аларның ресурсларын саклауны тәэмин итүче ысуллар белән башкарылырга тиеш (16 пункт);<br>– каен суты әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәренә кимендә 5 ел калгач рөхсәт ителә (17 пункт);<br>– башка төрле азык-төлек ресурслары әзерләү аларның үрентеләре торышына зыян салмый торган ысуллар белән башкарылырга тиеш; үсемлекләрне тамырлары белән өзеп алырга, яфракларына (ботакларына) һәм тамырларына зыян салырга рөхсәт ителми (18 пункт). |
| 5. | Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру | Яшел зоналарда урнашкан һәм урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда, шулай ук шәһәр урманнары территорияләрендә аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешенең 2 пункты). |
| 6. | Авыл хуҗалыгы алып бару | Су саклау зоналарында урнашкан урманнарда, печән чабу һәм умартачылыктан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 113 статьясының 2 пункты).<br>Яклагыч урманнарның яр буе чикләрендәге җирләрне сөрү, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү һәм алар өчен җәйге лагерьлар, ванналар оештыру тыела (Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясының 17 өлешендәге 1, 3 пунктлары).<br>Урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешендәге 3 пункты).<br>Яшел зоналарда урнашкан урманнарда, печән чабу һәм умартачылыктан, шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында киртәләп алулардан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 4 өлешендәге 2 пункты).<br>Махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә, печән чабудан һәм умартачылыктан кала, авыл хуҗалыгын алып |

| Тәртип саны | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 119 статьясының 4 өлешенең 2 пункты). |
| 7. | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Урманнарны фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм аның чикләрендәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату (2011 елның 23 декабрендәге 548 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләренең 9 пункты).<br>Агулы химик препаратларны куллану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 112 статьясының 4 өлеше, 113 статьясының 1 өлеше, 114 статьясының 2 өлешнең 1 пункты, 4 өлешенең 1 пункты). |
| 8. | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә табигый ландшафтлар, хайваннар дөньясы объектлары, су объектлары сакланырга тиеш (Россия Федерациясе Урман кодексының 41 статьясының 3 өлеше).<br>2012 елның 21 февралендәге 62 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>– рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә зыян китерми торган ысуллар ярдәмендә башкарыла (6 пункт);<br>– вакытлы корылмаларны, физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техника корылмаларын вакытлыча урнаштыру барыннан элек агачсыз һәм куаксыз урыннарда, ә мондый урыннар булмаганда – артык кыйммәтле булмаган агачлар белән капланган, урманнарны үзләштерү проектында билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә (8 пункт). |
| 9. | Урман плантацияләре утырту һәм аларны эксплуатацияләү | Плантация ясау максатларында түбәндәгеләрне файдалану рөхсәт ителми:<br>а) су саклау зоналарында урнашкан урманнарны;<br>б) табигый һәм башка төрле объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнарны;<br>в) кыйммәтле урманнарны;<br>г) махсус яклана торган урман кишәрлекәрендә урнашкан урманнар. |

| Тәртип саны | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 10. | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү | 2011 елның 05 декабрендәге 510 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>- җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләр, шулай ук урманга әверелмәгән диләнкеләр, аланнарны һәм аларга урман культураларын утыртканчы урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман үсемлекләре белән капланмаган җирләр; рекультивацияләнергә тиешле (эшләнелгән торфлыклар һ.б.) (11 пункт) җирләр файдаланыла.<br>- җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен –үстерү өчен үзгәртеп коруга билгеләнмәгән, азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин (12 пункт);<br>- Россия Федерациясе Урман кодексының 60.15 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләреннән җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану тыела. |
| 11. | Урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү | 2011 елның 19 июлендәге 308 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан урман үсемлекләренең утырту материалын үстерү өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен, иң беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урман белән капланмаган җирләрне, шулай ук урмансыз диләнкеләрне, аланнарны һәм башка, урман үсемлекләре белән капланмаган, урманнар урнашкан бүтән категория җирләре файдаланыла (11 пункт);<br>урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары, яки, әгәр андый орлыклар булмаса, урман үсемлекләренең нормаль орлыклары кулланыла (12 пункт);<br>урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең районнарга бүленмәгән орлыкларын, шулай ук сыйфаты тикшерелмәгән урман үсемлекләре орлыкларын, чәчүлекләрен һәм башкаларын куллану тыела (13 пункт);<br>Россия Федерациясе Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен урман утыртмаларының утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану Россия Федерациясе |

| Тәртип саны | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | Урман кодексының 60.15 статьясы нигезендә тыела. |
| 12. | Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару | Яшел зоналарда һәм урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда файдалы казылма ятмаларын эшкәртү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешенең 4 пункты, 4 өлешенең 1 пункты).<br>Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару максатында урманнардан файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) бульдозер ярдәмендә агачлар аудару һәм урман кишәрлекләрен агач үсемлекләреннән чистарту, чик буе полосаларын һәм урман авызларын агач калдыклары белән чүпләү, урман авызындагы агач кәүсәләрен һәм скелет тамырларын зарарлау, җәйге чорда яңа киселгән агачларны махсус чараларсыз гына урманда саклау;<br>б) урман утыртмаларын суга батыру һәм озак итеп су бастыру;<br>в) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфракны зарарлау;<br>г) урманнарны төзелеш, сәнәгать, агач, көнкүреш һәм бүтән калдыклар, чүпләр белән чүпләү;<br>д) бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>е) ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап, шул исәптән урман кишәрлегеннән читтә транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда йөрү (2010 елның 27 декабрендәге 515 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча файдалану тәртибенең 18 пункты). |
| 13. | Сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү | Тыюлы урман кишәрлекләрендә сусаклагычлар, башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 119 статьясының 3 өлешендәге 5 пункты). |
| 14. | Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү | Урманнарны линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм тапшырылган урман кишәрлегеннән читтәге янәшә урнашкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм |

| Тәртип саны | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) тапшырылган урман кишәрлеге һәм тиешле сак зоналарыннан читтә ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда йөрү (2011 елның 10 июнендәге 223 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләренең 15 пункты).<br>Урман паркы зоналарында урманнарда линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм алардан файдалану максатларында урманнардан файдалану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешендәге 5 пункты). |
| 15. | Агач һәм башка урман ресурслары эшкәртү | Яклагыч урманнарда, шулай ук махсус якланучы урман кишәрлекләрендә урман эшкәртү инфраструктурасы ясау тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 14 статьясының 2 өлеше).<br>Урманнарны үзагач һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) җир өсте һәм туфрак эче су агынтыларын бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә янәшә торучы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда йөрү (Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2014 елның 1 декабрендәге 528 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан агач материалы һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләренең 6 пункты). |
| 16. | Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру | Дини эшчәнлек башкарганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә өске һәм туфрак эче сулары агып төшүне бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеген һәм аның янындагы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач |

| Тәртип саны | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>г) ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буенча транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда үтеп керү. |

Гамәлдәге урман орлыкчылык объектларының нормативлары һәм параметрлары әлеге урман хуҗалыгы регламентында әзерләнми, урман орлыкчылык объектлары турында белешмәләр ел саен Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Дәүләт урман реестрын алып бару формаларын раслау турында» 2016 елның 06 октябрендәге 514 номерлы боерыгы белән расланган 14-ГЛР формасы буенча яңартыла.